УДК 398

***Л.Х. Мөхәммәтҗанова***

# КҮРЕНЕКЛЕ ОСТАЗЫМ Ф. УРМАНЧЕЕВ ҺӘМ АНЫҢ ЭПИК ҮЛЧӘМЛЕ ДӨНЬЯСЫ

***(галимнең тууына 90 ел тулу уңаеннан)***

В статье представлен краткий обзор жизненного и творческого пути выдающегося татарского ученого-фольклориста, эпосоведа, доктора филологических наук, профессора Фатиха Ибрагимовича Урманчеева (1936–2021), чья научная деятельность составила целую эпоху в изучении тюркского героического эпоса и татарской мифологии. Ф. Урманчеев обладал энциклопедическим кругозором, соединял в своих исследованиях историко-этнографический подход с глубоким литературоведческим анализом. Автором статьи анализируются ключевые этапы формирования ученого как исследователя тюркского героического эпоса. В работе показана эволюция его научных интересов: от первых работ по татарскому фольклору до фундаментальных трудов в области эпосоведения и мифологии. Особое внимание уделено таким исследованиям Ф.И. Урманчеева, как трехтомный энциклопедический словарь «Татарская мифология» (2008–2011) и учебник для вузов «Татарское народное творчество» (2002). Автор характеризует вклад Ф.И. Урманчеева в развитие изучения тюркского и татарского эпоса и его роль в формировании научной школы татарской фольклористики.

**Ключевые слова:** эпосовед Ф.И. Урманчеев, татарский фольклор, научно-педагогическая деятельность, дастаны, мифология

The article provides a brief overview of the life and creative path of the outstanding Tatar folklorist, epic scholar, Doctor of Philology, Professor Fatih Ibragimovich Urmancheev (1936–2021), whose scientific activity constituted an entire epoch in the study of the Turkic heroic epic and Tatar mythology. F. Urmancheev possessed an encyclopedic outlook, combined in his research a historical and ethnographic approach with a deep literary analysis. The author of the article analyzes the key stages of the formation of a scientist as a researcher of the Turkic heroic epic. The work shows the evolution of his scientific interests: from his first works on Tatar folklore to fundamental works in the field of epic studies and mythology. Special attention is paid to such studies by F.I. Urmancheev as his invaluable monographs, the three volume encyclopedic dictionary “Tatar Mythology” (2008–2011) and the textbook for universities “Tatar Folk Art” (2002). The author characterizes F.I. Urmancheev’s contribution to the development of the study of the Turkic and Tatar epos and his role in the formation of the scientific school of Tatar folklore.

**Keywords:** epic scholar F.I. Urmancheev, Tatar folklore, scientific and pedagogical activity, dastans, mythology

Татар фәнендә чал тарихның үзе кебек үк борынгы, бай, четерекле, тирән һәм тәэсирле, бүгенгенең рухи тамырларын тәшкил иткән, «халык иҗаты» дип аталган гаҗәеп мәгънәле бер өлкә бар. Төбендә энҗе-мәрҗәннәр тулы мул сулы дәрья белән дә чагыштырырга мөмкин аны. Халкыбызның шушы гаять үзенчәлекле җәүһәрләре бүгенге

ясалма фәһем чорында асылташтай балкый, игътибарны җәлеп итә, ихтыярсыз сокландыра, үткәнебез өчен горурлык тудыра, тарихи хәтеребезне яңартып, киләчәккә өмет кабыза икән, димәк, фәннең әлеге тармагында талантлы галимнәребез шактый күп көч куйган. Халкыбыз мирасының тарих тузанына күмелеп калмавына, тиешле югарылыкта халыкка җиткерелүенә, башка халыклар сафында горур яңгырарлык ядкәрләребезнең сакланып калуында да зур өлеше бар бу шәхесләрнең.

Шундый галимнәрнең берсе – гомере буе фольклор әсәрләрен гасырлар тирәнлегеннән сөзеп алып, безнең чорга якынайту, кыйммәтен билгеләп, киләчәк буынга тапшыру белән шөгыльләнгән эпос белгече, эрудит-галим Фатих Ибраһим улы Урманчеев (1936–2021). Бөтен гомерен халкыбызның эпик һәм лиро-эпик мирасын туплауга, шул ядкәрләрне өйрәнүгә, халыкның үз байлыгын үзенә кире кайтаруга багышлаган фидакяр зат иде Фатих ага. Фән юлын матур узган галимнәрнең берсе булды ул. Аның хакында татарның мәгълүм галимнәре, язучылары һәм хәтта шагыйрьләре шактый язды. Барысы да Фатих Урманчеевны татарның милли җанлы затлы галиме дип раслый. Мондый асыл шәхесләребез хакында кат-кат сөйләү, аңа хас сыйфатларны ассызыклау, казанышларына янә игьтибарны юнәлтү артык була алмый.

Үзе дә шагыйрь җанлы Фатих абыйның үзеннән дә, сүз сөрешеннән дә, басылган хезмәтләреннән дә теләсә кайсы чор өчен һәм теләсә кайсы катлау өчен тансык җуелмас кыйммәтләр – затлылык, галимлек, яхшы мәгънәсендәге эрелек, аксакаллык, тирәнлек һәм киңлек, ваклыклардан һәрвакыт өстен кала белгән олуглык, шулар белән бергә нечкә күңеллелек бөркелә иде. Болар – һәркемне тартып тора торган күркәм сыйфатлар һәм аларның сирәк кешедә очрый торганнары.

Фатих аганы хезмәтләре аша студент вакытымнан ук белсәм дә, аның үзе белән аралашып эшләү бәхетенә Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтына килгәч ирештем. Язмышымның бәхетле сукмагы үз вакытында Институтның нәкъ менә шушы олпат шәхес җитәкчелек иткән халык иҗаты бүлегенә алып килүне мин тормышымдагы иң уңышлы вакыйгалардан дип саныйм. Төрки дөньяда исеме билгеле зур галим Фатих Урманчеев үз өлкәсендә дистәгә якын фән кандидаты, берничә фән докторы әзерләде. Ул әзерләгән яшьрәк буын бүгенге көндә галимнең хезмәтләрен өстәл китабы итеп тота. Гап-гади кебек тоелган мөнәсәбәтләр артына зур галимнең фәнни тырышлыгы гына түгел, оста педагогик эшчәнлеге, сизгер психолог булуы, эшкә дәртләндерә белүе, алдан күрүчәнлеге, кече күңеллелеге һәм, әлбәттә, башка гаҗәеп сыйфатлары белән бергә, үз урынында үзенең булуы, галим кеше нинди була дигәндә, аның шәхси үрнәгенең югары дәрәҗәдә торуы яшеренгән. Фатих Урманчеев – татар халкының киләчәге турында алдан уйлап, сиздерми генә кайгырта белә торган чын милләтпәрвәр-остаз иде. Күренекле Хәмит Ярмиләр нигез салган, бүгенге

көндә фән дөньясында танылу алган Казан фольклор мәктәбенең иң якты йолдызы, олы ихтирамга лаек могтәбәр шәхесебез ул Фатих ага.

Быелның 28 маенда Фатих Урманчеевка 90 яшь тулган булыр иде. Гомер юлы һич кенә дә заяга үтмәде, гаять дәрәҗәдә нәтиҗәле булды аның. Фатих Ибраһим улы узган юл – татар халкы өчен бәрәкәтле нәтиҗәгә ия олы фән юлы. Себер киңлекләренең тугыз гына йортлы бер авылында дөньяга килеп, үз гомерендә халкы өчен шактый зур эшләр эшләргә өлгерде, төрки фән дөньясында мәгълүм зат булып танылды ул.

Фатих Ибраһим улы Урманчеев 1936 елда Омск өлкәсенең Азов районы, Кызыл Маяк авылында туа. 1955 елда Омск дәүләт педагогия училищесын, 1960 елда Омск дәүләт педагогия институтының киңәйтелгән тарих һәм филология факультетын тәмамлый. Студент елларында ук халык иҗаты белән кызыксына, доцент В.А. Василенко җитәкләгән фольклор түгәрәгенең старостасы булып, түгәрәк эшчәнлегендә актив катнаша, рус студентлары алдында татар халык җырлары, бәетләренә багышланган эчтәлекле чыгышлар ясый, Мәскәүдә чыгып килә торган «Русский фольклор» альманахында исә бу хакта мәгълүматлар басыла. Булачак галимнең халык иҗаты белән кызыксынуы шушы чорда ук башлана.

Институтны тәмамлаганнан соң ул туган ягындагы Сосновка авылы урта мәктәбендә ике елга якын укыта. Ф.И. Урманчеевта өметле яшь белгечне күреп алган Казан галимнәре И. Надиров һәм Э. Касыймов 1962 елда аны Татарстан башкаласына, Г. Ибраһимов исемендәге институтка аспирантурага чакыралар. Егет тәкъдимне кабул итә, язмышы аны менә шулай нурлы Казан белән бәйли.

Аспирантураны тәмамлагач, 1965–1969 елларда Ф.И. Урманчеев шул ук институтның халык иҗаты һәм халык сәнгате тарихын өйрәнү секторында кече фәнни хезмәткәр булып эшли, 1968 елда «Татар совет халык иҗатында төп жанрларның үсеш юллары» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый. 1961–1971 елларда ул – Казан дәүләт педагогия институтының рус һәм чит илләр әдәбияты кафедрасында әүвәл ассистент, соңыннан укытучы-доцент хезмәтендә эшли. 1971 елдан Ф.И. Урманчеев Алабуга педагогия институтында дүрт ел буе институтның читтән торып уку бүлеге проректоры, 1975 елдан уку-укыту эшләре буенча проректоры була. Язмышы һәм СССР Мәгариф министрлыгы тәкъдиме галимне чит җирләрдә дә йөртә: 1980–1984 елларда ул Венгриядә махсус командировкада булып, Эгер шәһәрендәге педагогия институты студентларына рус әдәбияты тарихын укыта. 1984 елда яңадан Алабугага кайтып, педагогик эшчәнлеген дәвам итә. Ә 1989 елда галим Ташкентта докторлык диссертациясе яклап, 1990 елда әдәбият кафедрасы профессоры дигән гыйльми исем ала. Ф.И. Урманчеевның әле чит илгә киткәнче үк язып тәмамланган, докторлык диссертациясенә бәрабәр, әмма ул еллар өчен гаять шикле саналган «Татар халкының героик эпосы» дип аталган зур хезмәте исә китап булып бераз соңрак дөнья күрә.

1992–2009 елларда галим – Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында (1996 елдан – Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты) халык иҗаты бүлеге мөдире, аннан соңгы елларда – бүлектә баш гыйльми хезмәткәр.

Ф.И. Урманчеевның иң зур хезмәтләре татар халык иҗатының эпик һәм лиро-эпик жанрларына багышланган: «Халык авазы: Татар халык бәетләре тарихыннан» (1974), «Эпические сказания татарского народа» (1980), «Героический эпос татарского народа» (1984), «Дастаннарга лаек замана: Борынгы фольклор һәм хәзерге поэзия» (1990), «По следам Белого волка: ранние этнокультурные связи тюрко-татарских племен» (1994), «Волшебный клубок: Муса Джалиль и народное творчество» (1995), «Идегәй. Нурсолтан. Сөембикә» (1997), «Народный эпос «Идегей» (1999), «Борынгы миф һәм бүгенге шигырь: Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин шигъриятенә бер караш» (2002), «Лиро-эпос татар Среднего Поволжья» (2002), Роберт Миңнуллин: шигъри осталык серләре (2005), «Каһарманнар йолдызлыгы: тарихи-фольклористик очерклар» (2006), «Татар мифологиясе: энциклопедик сүзлек. 3 томда» (1 том – 2008, 2 том – 2009, 3 том – 2011), «Тюркский героический эпос» (2015), «Татарский народный эпос» (2023). Гыйльми эшчәнлегендә төп урынны халык иҗаты алып торса да, галимнең эзләнүләре күпкырлы булды. Аны язма әдәбият, этнография, тарих, мифология мәсьәләләре тирәнтен кызыксындыра иде, ул бу мәсьәләләрне һәрвакыт гаять оста итеп татар фольклоры белән бәйләде. Ф.И. Урманчеевның һәр язганы, чын галимнәр хезмәтенә хас булганча, фәндә яңа сүз булып кабул ителә килде.

Аерым китап булып басылып чыккан дистәдән артык фәнни монографиясе, ул төзегән, татар мифологиясенә багышланган өч томлы уникаль энциклопедиясеннән тыш та әле галим – вузлар өчен татар халык авыз иҗатыннан төзелгән иң беренче дәреслек (2002) һәм хрестоматия (2004), көндәлек матбугатта фольклор, тарих темаларына һәм тарихи шәхесләр турында, язучы-прозаиклар һәм бигрәк тә шагыйрьләр иҗатына, әдәбият-мәдәниятнең актуаль проблемаларына, гыйльми хезмәтләргә багышланган өч йөзгә якын фәнни мәкалә, очерклар, рецензияләр һ. б. авторы.

Ф.И. Урманчеев – Татарстанның атказанган фән эшлеклесе (1996), Халыкара төрки академия академигы (1997) иде, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе Язучылар берлеге әгъзасы да булып торды.

Гомере буе халкыбызның фольклор хәзинәсен барлаган, аның биниһая могҗиза булуына төшенеп, башкаларга да бу өлкәнең мавыктыргыч серләрен ачкан, эпос-дастаннар дөньясына дәшеп, үз артыннан ияртә белгән көчле фикерле, күренекле татар галиме иде Фатих Ибраһим улы Урманчеев. Фәннең шактый катлаулы, филология һәм тарихи фәннәрдән генә дә түгел, фәлсәфә, дин гыйлеме

һ. б. өлкәләрдән дә гаять киң мәгълүматлы булуны таләп итә торган фольклористикага мөкиббән чын галим иде. Дөресен әйткәндә, андыйлар бик сирәк, галимнәр арасында аның кебеге башка юктыр да. Фикер колачы киң булды, яхшы гамәлләре бихисап иде, әйткән сүзе һәрвакыт зиһен ачыклыгына этәрде Фатих аганың.

Галимнең эпос-дастаннар, мифология өлкәләрендәге тирәнтен тикшеренүләре милли рухи мирасыбызның үзәк проблемаларын фәнни дәрәҗәдә ачуга нигез салды, татар фольклорын системалы өйрәнүнең яңа юнәлешләрен билгеләде. Галим татар халкы өчен генә түгел, бөтен төрки дөнья һәм эпос фәне белгечләре өчен зур әһәмияткә ия фәнни хезмәтләр калдырды. Гыйльми казанышлары, якты исеме, яхшы даны онытылмас Фатих Ибраһим улының. Фәндә ул юл күрсәткән затлар шактый һәм аны үзенең остазы санаучылар татар галимнәре генә дә түгел; бөтен төрки дөнья фольклорчы галимнәре, шулай ук Идел-Урал төбәге эпос белгечләре Фатих Урманчеевның зур галим булуын таныйлар, аны ихлас сагынып искә алалар. Шунысы куанычлы: галимнең эше бүгенге көндә исән – Ф.И. Урманчеев фәнни мәктәбе үз эшен киң колач белән дәвам итә, ә аның хезмәтләре киләчәк буын галимнәре өчен әһәмиятен югалтмый. Бу юбилей – тик бер дата гына түгел, ә галимнең фольклористикага керткән өлешенә тирән ихтирам һәм татар фәнендә аның тоткан урынын тагын бер кат раслау мизгеле.

***Мөхәммәтҗанова Лилия Хатип кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

***Мухаметзянова Лилия Хатиповна,***
*доктор филологических наук, главный научный сотрудник отдела народного творчества Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*

*lilmuhat@mail.ru*